# Тамчы

2005 елның
1 ноябреннән
чыга

Сишәмбе
11 февраль
2014 ел

## *Фатих Кәримнең тууына 105 ел*

**Бөгелмә муниципаль районының
муниципаль бюджет гомуми белем бирү
учреждениесе
7нче гимназия**

Бу чыгарылышта:

1 бит: Фатих Кәрим турында фикерләр

2 бит: Фатих Кәримнең тормыш һәм иҗат юлы

3 бит: Шагыйрьнең туган-нарына хатлары

4 бит: Шигъри мизгелләр

5 бит: Укучылар иҗаты

6 бит: Фатих Кәрим безнең күңелләрдә

7 бит: Тапкырлар һәм зирәкләр өчен

8 бит: Фатих Кәрим иҗатына багышланган кроссворд



***"Фатих Кәрим – һәр шигырь юлы белән ватанына фидакарь хезмәт иткән җырчы һәм солдат. Аның Казан музеенда изге реликвия булып саклана торган шинеле генә түгел, кулъязмаларының соңгы битләренә кадәр пулялар белән тишкәләнеп беткән".***

***Луи Арагон***

***Иҗатының беренче чорыннан ук ( 1927 – 1932 еллар ) Фатих Кәрим – шагыйрь, көрәшче һәм патриот. Әдәбиятка килгән елларыннан ук үзенең зәвыклы, тырыш иҗатчы булуын күрсәтә. Аның Мирсәй Әмир, Хәсән Туфан, Кави Нәҗми кебек якын дуслары Фатих Кәримнең хезмәт сөючән, эшлекле, пөхтә, үз-үзенә дә, иптәшләренә дә игътибарлы, таләпчән, олы җанлы кеше булуы турында язалар.***

***"Дөнья хәлләре кискенләшкән саен нигәдер Фатих Кәрим кебек кешеләр искә төшә. Ә бит Фатих Кәрим – Бөек Ватан сугышы шагыйре. Бүгенге дөнья белән узган сугышның арасы нигә шулай якыная? Ике кырыс чор. Татар совет поэзиясендә шул чорны Фатих Кәримнән дә тулырак чагылдырган башка бер шагыйрь дә юк. Кенигсберг янында сугышның бөек үренә күтәрелде, үзенең иҗат үренә күтәрелде, үз шөһрәтенә шул солдат үреннән карап үлде. Үзенә йөкләнгән зур эшне башкарып китте шагыйрь."***

***Сибгать Хәким***

# Фатих Кәримнең тормыш һәм иҗат юлы



*Әхмәтвәли улы Фатих Кәримов 9 гыйнварда Башкортстандагы Бишбүләк районы Ает авылында мулла гаиләсендә 11нче төпчек бала булып дөньяга килгән. Әниләре балаларына әкиятләрне, бәетләрне яттан сөйләгән. Гаиләдә һәр кеше шигырьгә гашыйк булган. Кечкенә Фатих әнисен елата-елата Сак-Сок бәетен укыган. Апасы Мәрьям, абыйсы Габдулла да шигырьләр язган. Аларның йогынтысы Фатихка да тигәндер, күрәсең.*

*13 яше тулгач, аны, абыйсы Габдулла Бәләбәйдәге педагогия техникумының әзерлек курсларына урнаштыра. Ике ел укыгач, Фатих Казандагы Н.К.Крупская исемендәге балалар йортында тәрбияләнә. 1925-1929 елларда Казан җир төзү техникумында укый. Булачак хатыны - Кадрия Ишукова белән дә шунда таныша.*

*Фатих та, Кадрия дә язу сәләтенә бик оста булганнар. Фатих ару-таруны белми каләмен чыныктыра. Башта ул мәкаләләр фельетоннар, ә соңрак шигырьләр, хикәяләр, ялкынлы поэмалар яза башлый. Фатих Кәрим 1931 елда армиягә алына. 1933 елның гыйнварына кадәр Идел буе хәрби округының Казанда чыга торган “Кызылармияче” газетасында хәрби журналист-хәбәрче булып хезмәт итә. Хезмәттән соң төрле газета-журнал редакцияләрендә эшли, Татар дәүләт нәшриятының яшьләр-балалар әдәбияты секторы җитәкчесе була, зур әдәби мәктәп үтә.*

*1937 елның җәй айларында күп язучылар һәм шагыйрьләр белән аны да “халык дошманы” ясамакчы булалар. Ул кулга алына. 1941 елның 3 декабрендә аны аклыйлар. Ул үзе теләп сугышка китә. 1942 елның 19 апрелендә “хәбәрсез югалды” дигән язу килә, ләкин шул ук елның 1 маенда Фатих Кәрим Казанга кайта, ай ярым госпитальдә дәвалана. Шунда ул “Кыңгыраулы яшел гармун” поэмасын иҗат итә, күп кенә шигырьләрен язып газеталарга бирә.*

*Соңгы сулышына кадәр батырларча көрәшеп, үзенең сугышчылары белән немецларның 45 офицерын һәм солдатын үтерә, 120 немецны әсир итә. Хәрби батырлыклары өчен Кызыл Йолдыз ордены, I дәрәҗә Дан ордены, бернечә медаль белән бүләкләнә. Җиңү көненә санаулы гына атналар калганда, хәлиткеч көрәштә яраланып, кече лейтенант, взвод командиры Фатих Кәрим, 1945 елның 19 февралендә батырларча һәлак була. Дуслары-көрәштәшләре пулядан теткәләнгән шинелен, шигырь дәфтәрләрен, хатларын һәм итеген Казанга язучылар дәүләт музеена җибәрәләр, ләкин анда янгын чыгып, бик күп кыйммәтле экспонатлар арапителә. Фатих Кәримнең Ленинградка җибәрелгән шинеле генә аның геройларча үлемен хәтерләтә.*

### *Теләк*

*Матурлык сайлауда мине*
*Кем куып җитәр икән?!*
*Сөюдә һәм сөелүдә*
*Мине кем җиңәр икән?!*

*Яшәдем, яшел урманнар*
*Иркәләде, көйләде.*
*Инде мин сугыш кырында,*
*Тик бер генә теләгем:*

*Дошманга ялкын сибүче*
*Җил булып барсам иде,*
*Тәвәккәлек, батырлыкта*
*Җыр булып калсам иде.*

## *Шагыйрьнең хәле, кичерешләре, көрәше һәм яшәү дәрте аның ут астында язган хатларында ачык чагыла:*



*Кызым минем, Ләйләм!*

*Сиңа әтиеңнән кайнар сәлам. Мин сине бик сагындым, күрәсем килә. Әниең миңа фотокарточкаларыгызны җибәрәм дип вәгъдә иткән иде, ләкин минем аны алганым юк бит әле. Алсам, бик шатланыр идем.*

*Я, Ләйлә, ничек яшисең, балалар бакчасында ниләр эшлисең? Әниеңә ничек булышасың? Сез әниеңне яратыгыз. Адага да әйт, әниегез моңаймасын. Аңа булышыгыз, сүзен тыңлагыз. Ул сезгә бервакытта да ачуланмасын. Минем “Әткәем” дигән һәм башка шигырьләремне китаптан укып күңелдән сөйләргә өйрән. Кайткач, тыңлатып карармын. Кызым, исән-сау бул. Минем өчен әниеңне һәм Аданы үп.*

*Сине бик-бик яраткан әтиең Фатих.*

*15 февраль, 1943*

*Кызчыгым Ада, кадерлем!*

*Әтиеңнән кайнар фронт сәламе сиңа. Кадерле әниеңә һәм яраткан сеңлең Ләйләгә миннән сәлам әйт. Кызчыгым, мин хәзергә исән-сау әле. Тик минем һич кенә дә вакытым юк. Соңгы өч ай эчендә бер дә яңа әйбер язганым юк.*

*Ә син, Адочка, бар көчеңне җыеп яхшы укырга тырыш, чөнки барлык фронтовикларның – Туган илебезне саклаучыларның – балалары “отлично”га һәм “яхшы” билгеләләренә укырга тиешләр. Һәрвакыт әниеңнең сүзен тыңла, өй эшләрендә булыш. Бик каты кочаклап үбеп калам.*

*Әтиең Фатих.*

*10 февраль, 1944.*





*Сөекле Кадриям, күз нурларым – кызларым!*

*Сезгә ерактан сагынычлы сәлам. Шулай ук мине сораганнарга сәлам. Үзем хәзергә исән-сау. Бөтен көчем белән тырышып, көн-төн эшләп ятам. Тик язарга гына вакыт аз. Мин “Разведчик язмалары” дигән повесть яздым һәм аны бүген акка күчереп “Совет әдәбияты” журналына җибәрдем. Так что, син мине эшләми ялкауланып йөри дип уйлама. Хәзер синең бурычың: минем ул әсәремнең редакциягә барып җитүен сорашып, тикшереп белү. Җай тапсаң, алып укып чыгу. Инде алдымда ике әйбер тора: теге пьесаны бетерү һәм Кызыл Армиянең һөҗүменә багышланган кыскарак бер поэма язу. Өстәвенә мин төнлә белән генә эшли алам, көндез һич вакытым юк.*

# Шигъри мизгелләр

### Җиңү җыры

*Без яшенле давыл кебек*
*Айкап  киләбез.*
*Илгә бәхет, шатлык даулап*
*Утка керәбез.*

*Кичәбез киң дәрьяларны,*
*Урман, тауларны.*
*Давыл кебек туздырабыз*
*Дошман ояларын.*

*Без ант иттек, куроклардан*
*Кулны алмабыз,*
*Бөтен дошман берләшсә дә,*
*Җиңми калмабыз.*

*Бу җиңүнең онытылмаслык*
*Данлы булуын*
*Иң матур җыр итеп җырлар*
*Киләчәк буын.*

### Ант

*Юлбасарлар таптый җиребезне,*
*Ватан сугышына мин китәм.*
*Менә — балам. Син әнкәсе аның,*
*Балабызны тотып ант итәм.*
*Синең өчен, шушы балам өчен,*
*Нәселем өчен, Туган ил өчен,*
*Мылтык тотып баскан җиремнән*
*Бер адым да артка чигенмәм...*
*Бәлки, соңгы тапкыр — күрештек,*
*Кочаклаштык, озак үбештек.*
*Сизә бала, карый күзләремә:*
*«Сакла безне!» — ди ул күңеленнән,*
*Ана күкрәгеннән суырып алган*
*Сөт тамчысы алсу иренендә.*
*Шушы балам өчен, синең өчен,*
*Нәселем өчен, Туган ил өчен,*
*Мылтык тотып баскан җиремнән*
*Бер адым да артка чигенмәм.*




### Ватаным өчен

*Бәлки, бу хат соңгы хатым булыр,*
*Иң дәһшәтле утка керәмен,*
*Шулай була калса, кояшны да*
*Бүген соңгы тапкыр күрәмен.*
*Мин сугышка керсәм, дошманымның*
*Йөрәгенә төзәп атамын;*
*Үзем үлсәм, балаларым кала*
*Минем гомерем булып, Ватаным.*
*Кала дөнья, кала бар матурлык,*
*Ал чәчәкләр кала болында,*
*Чәчәкләргә төренеп эзем кала,*
*Җырым кала үткән юлымда.*
*Үләм икән, үкенечле түгел*
*Бу үлемнең миңа килүе,*
*Бөек җыр ул — Бөек Ватан өчен*
*Сугыш кырларында үлүе.*

# Укучылар иҗаты



Үлемсез шагыйрь.
Башкортстан синең туган җирең,
Милләтең синең татар.
Татар–башкорт бергәләшеп
Үстергәннәр бер батыр.

Син тугансың авыр, кырыс елда,
Һөкем сөргән илдә явызлык,
Йөрәгендә көч һәм дәрман булган,
Туры юлдан алга барырлык.

Еллар үткәч, Казаннарга барып
Тырыша-тырыша белем алгансың,
Ул вакытта беркем әйтә алмаган
Җиргә герой-шагыйрь туасын.

Синең гомер бигрәк кыска булган,
Язмыш шундый гомер юраган,
Дошман уты сине һәлак иткән
Тик халык сине оныта алмаган.

6нчы А сыйныфы укучысы,
Ситдикова Лилия















# Фатих Кәрим безнең күңелләрдә


ДИПЛОМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БӨГЕЛМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫНЫҢ МӘГАРИФ ИДАРӘСЕ

*Татар шигъриятенең горурлыгы*
*Фатих Кәримнең 105 еллык*
*юбилеена багышланган*
*"Гөр-гөр гөрләшик"шигырь сөючеләр*
*конкурсында актив катнашучы*

Ситдикова Лилиягә
7нче гимназия укучысы

(укытучысы Әхметшина Э.Р

*тапшырыла*

*Мәгариф идарәсе башлыгы* *В.В.Кульбеда*

2013

7нче февраль көнне 14нче татар гимназиясендә татар шигъриятенең горурлыгы— Фатих Кәримнең 105 еллык юбилеена багышланган "Гөр-гөр гөрләшик" район күләме шигырь сөючеләр конкурсы булып узды. Анда 6нчы А сыйныфы укучысы Ситдикова Лилия Фәтих Кәримгә багышлап үзе язган шигырен сөйләде һәм актив катнашучы булларак дипломга лаек булды.



Февраль аенда сөекле шагыйребез Фатих Кәримнең 105 ел тулу уңаеннан гимназиябездә төрле чаралар үткәрелде. Шуларның берсе – "Фатих Кәрим – герой-шагыйрь" дип исемләнгән әдәби искә алу кичәсе булды. Әлеге кичәдә 7нче сыйныф укучылары Фатих Кәримнең тормыш юлы һәм иҗаты белән таныштырдылар, аның сугышта язылган шигырьләрен яңгыраттылар.



Укучыларның игътибарын бигрәк тә шагыйрьнең иҗаты һәм тормыш юлына багышланган фильм җәлеп итте. Алар ребуслар, кроссвордлар чишү буенча ярыштылар. Фатих Кәрим әсәрләре буенча 5-8нче сыйныф укучылары тарафыннан ясалган иллюстрацияләр барлык катнашучыларны сокландырды.








# Тапкырлар һәм зирәкләр өчен

*Фатих Кәримнең тормыш юлы һәм иҗаты буенча викторина*

1. Фатих Кәрим кайда һәм кайчан туган?
2. Аның шагыйрь булып китүенә нәрсә яки кем этәргеч биргән?
3. Башлангыч чор иҗатыннан нинди әсәрләрен беләсез?
4. Фатих Кәримнең яраткан шагыйрьләрен атарга.
5. Бөек Ватан сугышына кадәр язылган нинди күләмле әсәрләрен беләсез?
6. Ул сугышка кайчан китә?
7. Гаиләсе турында ниләр беләсез?
8. Сугыш чорында язылган поэмалары ничәү? Исемнәрен атарга.
9. Фатих Кәрим кайда һәм ничек һәлак була?
10. Фатих Кәримнең фронт юлы турында нәрсә беләсез? Ул кайда җирләнгән? Кайсы елда табыла?
11. Фатих Кәрим фронт юлын рядовой солдат булып башлый. Нинди дәрәҗәгә күтәрелә? Нинди бүләкләрен беләсез?
12. Шагыйрьнең хатыны Кадрия Ишукова иренә багышлап нинди гөл үстерә?
13. Фатих Кәримне аклауга кемнәрнең ярдәме тигән?
14. Фатих Кәрим исемен мәңгеләштерү буенча республикада ниләр эшләнгән?
15. Фатих Кәримнең кайсы шигырьләренә көй язылган?
16. Туган якларга Фатих Кәримнең нинди шәхси әйберләре кайткан?
17. Фатих Кәрим турында язылган нинди әсәрләр беләсез?

# Ребуслар















# Фатих Кәрим иҗатына багышланган кроссворд



**Сулдан уңга.** **5**. Ф.Кәрим поэмасы. **6**. Жанр. **8**. Бөек Ватан сугышында Ф.Кәрим кем булган? **10**. “... булып ... башын сузган судан”. **14.** “Иван бабай ... кигән”. **15.** “... суза Фазылга язгы чәчәк бәйләмен”. **16.** “ ... булып, гөлгә кунып, керәсең төшләремә”. **18.** Ф.Кәримнең кызының исеме. **19.** “... кадерле, дуслар, сугышта, сугышырга чөнки ... кирәк”. **22.** Ф.Кәримнең әтисенең исеме. **25.** “... бармак шартлатып ”. **26.** Ф.Кәримнең апасының исеме .

**Өстән аска.** **1.** Ф.Кәрим иҗат иткән шигырь. **2.** Ф.Кәрим иҗат иткән шигырь. **3.** “... әнкәй”. **4.** “Тып-тып-тып итә ... - ... тамчылар”. **7.** **“**Соңгы тапкыр карыйм ...”. **9.** “Тимер һәм тимерче” әсәренең жанры. **11.** “Озата Идел егетен ... кызы. **12.** “Улакка менеп баскан кыз, Кашка янына, кызыл ефәк бантик бәйли маңгай ...” . **13.** Ф.Кәримнең балалар өчен язган әсәре. **17.** “ Һәркем аның кебек сугышса, ... бетәр иде бу дошман”. **20.** “Үлем уены” поэмасындагы персонаж. **21.** “... үтә, ерагая бара”. **23.** “Шомырт чәчәгедәй ... , ягымлы, ... һәм йомшак синең күңелең”. **24.** “Дусларым юк хәзер, тик бирәүгә мин кулларын үбеп, баш ...”.


Баш редактор: Талипова Айгөл
Редактор: Әхмәтшина Альбина
Редколлегия: Ситдикова Лилия, Емельянова Елена, Шәйхуллина Камилә, Галимова Лилия.

Безнең адрес: Бөгелмә шәһәре, М.Җәлил урамы, 37нче йорт, 7нче гимназия.
E-mail: bg-7@mail.ru
Тел.: (85594) 4-20-01,
Тираж 100